КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 6 март г.Казань № б-490

Татарстан Республикасында эшче һәм инженер һөнәрләрен популярлаштыру эшен оештыру максатларында:

1. «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыятенең, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә, 2020 елның 17 августыннан 22 августына кадәр тигез хокуклы финанслашу шартларында «PROFХәрәкәт» яшьләр һөнәри юнәлеш бирү форумын үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне (боерыкка теркәләләр) расларга:

2020 елда «PROFХәрәкәт» яшьләр һөнәри юнәлеш бирү форумын оештыру һәм үткәрү чаралары планын;

«PROFХәрәкәт» яшьләр һөнәри юнәлеш бирү форумын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге форумны үткәрү чараларын «2019 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында эшче һәм инженер һөнәрләрен популярлаштыру» ярдәмче программасын тормышка ашыруга күздә тотылган акча исәбеннән 2,25 млн.сум күләмендә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына әлеге форумны әзерләү һәм үткәрү барышын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы

Премьер-министры
А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 6 март, б-490 нчы
карары белән расланды

2020 елда «PROFХәрәкәт» яшьләр һөнәри юнәлеш бирү форумын оештыру һәм үткәрү чаралары планы

| Т/с | Чаралар исеме | Тормышка ашыру вакыты | Җаваплы үтәүчеләр | Финанслауның күздә тотыла торган күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты | бюджеттан тыш акча |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | «PROFХәрәкәт» яшьләр һөнәри юнәлеш бирү форумында (алга таба – Форум) катнашучыларны сайлап алу максаты белән комплекслы чаралар оештыру һәм үткәрү | март – май | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча) | - | - | - |
| 1.1. | Форумда потенциаль катнашучыларны җәлеп итү | май – август | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | министрлыгы, гомуми белем бирү оешмалары (килешү буенча), һөнәри белем бирү оешмалары (килешү буенча) һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары (килешү буенча) | | | |
| 1.2. | Форумда катнашу өчен студентларны конкурс нигезендә сайлап алуны оештыру (көллиятләр һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары белән эшләү) | апрель – июль | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча) | - | - | - |
| 1.3. | Форумда катнашучылар составын билгеләү | август | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча) | - | - | - |
| 2. | Форумны оештыру | август | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, гомуми белем бирү оешмалары (килешү буенча), һөнәри белем бирү оешмалары (килешү буенча) һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары (килешү буенча) | 4 500,0 | 2 250,0 | 2 250,0 |
| 2.1. | Форумда катнашучыларның | август | Татарстан Республикасы Хезмәт, ха- | 1 900,0 | 1 900,0 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | яшәвен һәм тукlануын оештыру | | лыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | | | |
| 2.2. | Форумда катнашучыларның трансферын оештыру | август | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 350,0 | 350,0 | - |
| 2.3. | Техник белгечлекләр яктылыгында һөнәри юнәлеш бирү юнәлешендәге чараларны эшләү, оештыру һәм үткәрү | апрель – август | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча) | 270,0 | - | 270,0 |
| 2.4. | Техник белгечлекләр яктылыгында белем бирү-проект юнәлешендәге чараларны эшләү, оештыру һәм үткәрү | апрель – август | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча) | 300,0 | - | 300,0 |
| 2.5. | Шәхси үсеш чараларын эшләү, оештыру һәм үткәрү (интерактив иҗади чаралар, спорт чаралары, интеллектуаль уеннар, квестлар, экскурсияләр) | апрель – август | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча) | 300,0 | - | 300,0 |
| 2.6. | Форумда катнашучылар өчен тарату материалы җыелмасын һәм реклама-полиграфия продук- циясен әзерләү | июль | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча) | 650,0 | - | 650,0 |
| 2.7. | Җиңүчеләргә бүләкләр сатып алу | август | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча) | 300,0 | - | 300,0 |
| 2.8. | Тавыш операторы һәм диджей җәлеп итү, алып баручыны яллау | август | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча) | 85,0 | - | 85,0 |
| 2.9. | Фотога һәм видеога төшерүне оештыру һәм видеороликлар | август | «КАМАЗ» ГАҖ (килешү буенча) | 85,0 | - | 85,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм хисап фильмын әзерләү | | | | | |
| 2.10. | Чыгым материаллары белән тәэмин итү (канцелярия товарлары) | август | «КАМАЗ» ГАЖ (килешү буенча) | 100,0 | - | 100,0 |
| 2.11. | Форумны ачу һәм ябу тантаналары өчен залны тантаналы итеп бизәү | август | «КАМАЗ» ГАЖ (килешү буенча) | 150,0 | - | 150,0 |
| 2.12. | Форумның җиһазларын, товарматди кыйммәтләрен ташуны, оештыручыларны йөртүне оештыру | август | «КАМАЗ» ГАЖ (килешү буенча) | 10,0 | - | 10,0 |
| 3. | Форумны үткәрү тәҗрибәсен конкурсларда, түгәрәк өстәл утырышларында һ.б. катнашу аша төбәкләргә тарату | постоянно | «КАМАЗ» ГАЖ (килешү буенча) | - | - | - |
| 4. | Форум йомгаклары буенча аналитик һәм презентация материаллары, видео- һәм фотохисаплар әзерләү | октябрь | «КАМАЗ» ГАЖ (килешү буенча) | - | - | - |
| 5. | Форум кысаларында үткәрелә торган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту | апрель – август | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | - | - | - |
| | | | Барлыгы | 4 500,0 | 2 250,0 | 2 250,0 |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 6 март, б-490 нчы
боерыгы белән расланды

2020 елда «PROFХәрәкәт» яшьләр һөнәри юнәлеш бирү форумын оештыру һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, оештыру комитеты рәисе |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Когогин Сергей Анатольевич | «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Анфимова Алла Леонидовна | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары |
| Ганиев Мәхмүт Мәсхут улы | югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Яр Чаллы институты (филиалы) директоры (килешү буенча) |
| Окунева Юлия Михайловна | «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыятенең рекрутинг һәм кадрлар белән идарә итү методологиясе бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Поминов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сөләйманов Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары |
| Таҗетдинова Клара Алексеевна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Ульдяков Дмитрий Юрьевич | КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директорының персонал белән идарә итү һәм оештыру ягыннан үстерү буенча урынбасарының яшьләр белән эшләү буенча консультанты (килешү буенча) |
| Ушенин Александр Михайлович | КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директорының персонал белән идарә итү һәм оештыру ягыннан үстерү буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Хөсәенов Алмаз Шәүкәт улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары. |

___________________________